Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегенең Антоновка авылында узган халык җыены нәтиҗәләре турында

КАРАРЫ

2019 елның 9 декабре, № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Антоновка авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?: мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе төзелде:

- поселок эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 62 кеше, җыенда 35 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 35 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы составына керүче Красновидово авыл җирлегенең Антоновка авылында гражданнар җыенын узган дип һәм халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2.Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: "Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Антоновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- поселок эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Антоновка авыл җирлегендә яшәү урыны буенча

теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

- поселок эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

4. Халык җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк урамы, 3;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге
башлыгы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге
Советы рәисе В.П.Оленин